**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш XV утырыш
**КАРАРЫ**

2023 елның 31 октябре №56 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2009 елның 21 маендагы 168 номерлы карары белән расланган, Ышанычлы идарә шартнамәсен төзү хокукына конкурс уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 296-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2009 елның 21 маендагы 168 номерлы карары белән расланган, Ышанычлы идарә шартнамәсен төзү хокукына конкурс уздыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 4.10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүченең «Концессион нигезләмәләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә концессионерга куела торган таләпләргә туры килүе;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин